**Татарстан Республикасы**

**Арча муниципаль районы**
**Арча муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәре**
**Башкарма комитеты**

**422000, ТР, Арча ш., мәйдан Советы, 27**

**тел. 3-15-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**

**город Арск**

**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Исполнительный комитет**
**города Арск**
**422000, РТ, г.Арск, площадь Советская, 27**

**тел. 3-15-25, 3-12-35**

# КАРАР

**«_18_»___июнь___ 2021 ел** **№ 63**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитеты тарафыннан капитал салуларны яклау һәм хуплау турында килешүләр төзү Тәртибен һәм шартларын раслау хакында**

«Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм хуплау турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьяның 8 өлеше нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитеты тарафыннан капитал салуларны яклау һәм хуплау турында килешүләр төзү тәртибен һәм шартларын расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча халыкка җиткерергә: http://arsk.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе — Р.Ф. Касыймов

Арча шәһәре Башкарма комитетының
18 июнь 2021 ел, 63 номерлы
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитеты тарафыннан капитал салуларны яклау һәм хуплау турында килешүләр төзү тәртибе һәм шартлары**

1. Әлеге Тәртип “Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм хуплау турында” 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 8 өлеше (алга таба - Федераль закон) нигезендә эшләнгән һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитеты тарафыннан капитал салуларны яклау һәм хуплау турында килешүләр төзү шартларын һәм тәртибен билгели.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре башкарма комитеты тарафыннан капитал салуларны яклау һәм хуплау турында килешүләр төзү тәртибе.

2.1. Капитал салуларны яклау һәм хуплау турында килешүне төзүгә, үзгәртүгә һәм өзүгә, шулай ук әлеге килешү буенча бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләргә карата, Федераль законда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, граждан законнары кагыйдәләре кулланыла.

2.2. Федераль законның 10 статьясының 5 пункты нигезендә капитал салуларны яклау һәм хуплау турындагы килешү 2030 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча төзелә.

2.3. Капитал салуларны яклау һәм хуплау турындагы килешүдә түбәндәге шартлар булырга тиеш:

1) инвестицион проектны тасвирлау, шул исәптән инвестицион проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә җитештерелә, башкарыла яки төзелә торган акыл эшчәнлеге нәтиҗәләренә характеристикалар, аларның фаразланган күләме турында белешмәләр, аларга технологик һәм экологик таләпләр;

2) инвестицион проектны гамәлгә ашыру этапларын күрсәтү, шул исәптән:

а) проектны гамәлгә ашыру өчен кирәкле рөхсәтләр һәм ризалыклар алу срогы;

б) хокукларны, шул исәптән күчемсез мөлкәткә хокукны, акыл эшчәнлеге нәтиҗәләрен яисә индивидуальләштерү чарасын (кулланылу очрагында) дәүләт теркәвенә алу срогы;

в) инвестицион проект кысаларында (файдаланыла торган очракларда) төзелә, модернизацияләнә яисә реконструкцияләнә торган объектны эксплуатациягә кертү срогы;

г) федераль законда каралган тотрыклыландыру төзәтмәләрен куллану срогыннан артмаган күләмдә капитал салуларны гамәлгә ашыру срогы;

д) капитал салуларны яклау һәм хуплау турында килешүдә билгеләнгән башка чараларны гамәлгә ашыру срогы;

3) Федераль законда күрсәтелгән инвестицион проектны гамәлгә ашыру параметрларыннан иң чик тайпылышлар (25 процент чикләрендә) турында

белешмәләр, мөмкин булган иң чик тайпылышлар күрсәткечләре Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртип нигезендә билгеләнә, шул ук вакытта проектны гамәлгә ашыручы оешма керткән капитал салуларның күләме Федераль законның 9 статьясындагы 4 өлешендә каралган зурлыклардан кимрәк була алмый;

4) Федераль законда билгеләнгән сроклар чикләрендә тотрыклыландырылган төзәтмәләр куллану срогы;

5) Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктында күрсәтелгән субсидияләр, бюджет инвестицияләре бирү сроклары һәм күләмнәре, Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән кредит шартнамәсе буенча процент ставкасы (аны билгеләү тәртибе), шулай ук Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлешенең 2 пунктында күрсәтелгән субсидияләр бирү сроклары һәм күләмнәре;

6) гавами-хокукый берәмлеккә (гавами-хокукый берәмлекләр) Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле бюджеты акчалары исәбеннән проектны гамәлгә ашыра торган оешма файдасына проектны гамәлгә ашыручы (зыяннарны каплау бурычын үз өстенә алган Россия Федерациясе проектны гамәлгә ашыручы оешмаларны үз өстенә алган очрактан тыш) оешма тарафыннан исәпләнгән мәҗбүри түләүләр күләменнән артмаган күләмдә инвестицион проектны гамәлгә ашыру белән бәйле капитал салуларны яклау һәм хуплау турында килешүнең яклары булган гавами-хокукый берәмлекләрнең тиешле бюджетларына түләү өчен түләүләр башкару бурычына күрсәтмә, аерым алганда, оешмалар табышына салым, оешмалар мөлкәтенә салым, транспорт салымы, өстәмә кыйммәткә салым (проектны тормышка ашыручы оешмага кире кайтарылган салымнан тыш), таможня пошлиналары, җиңел автомобильләр һәм мотоциклларга акцизлар.

а) Федераль законның 12 статьясында каралган тәртип нигезендә чын зыянны каплауга, шул исәптән Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлешендә каралган очракларда;

б) Федераль законның 15 статьясында каралган тотылган чыгымнарны каплауга (гавами-хокукый берәмлек тарафыннан мондый чыгымнарны каплау турында карар кабул ителгән очракта);

7) проектны гамәлгә ашыручы оешма тарафыннан инвестицион проектны гамәлгә ашыру этаплары турында мәгълүмат бирү тәртибе;

8) капитал салуларны яклау һәм хуплау турындагы килешүнең яклары арасында бәхәсләрне хәл итү тәртибе;

9) Федераль законда каралган башка шартлар.

2.4. Килешү төзү турында карар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре Башкарма комитеты күрсәтмәсе рәвешендә кабул ителә.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре Башкарма комитеты тарафыннан капитал салуларны яклау һәм хуплау турында килешүләр төзү шартлары.

3.1. Капитал салуларны яклау һәм хуплау турындагы килешү проектны гамәлгә ашыручы оешма белән Россия икътисадының бер өлкәсендә яңа инвестицион проектны гамәлгә ашыруны күздә тоткан шарт белән төзелә, моңа

түбәндәге өлкәләр һәм эшчәнлек төрләре керми:

1) уен бизнесы;

2) тәмәке әйберләре, алкоголь продукциясе, сыек ягулык җитештерү (чикләү күмердән алынган сыек ягулыкка, шулай ук Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган исемлек нигезендә нефть чималын икенчел эшкәртүгә кулланылмый);

3) чи нефть һәм табигый газ, шул исәптән иярчен нефть газы чыгару (чикләү табигый газны сыекландыру буенча инвестицион проектларга карата кулланылмый);

4) күпләп һәм ваклап сату;

5) Россия Федерациясе Үзәк банкының күзәтүче финанс оешмалары эшчәнлеге (чикләү инвестицион проектны финанслау максатларында кыйммәтле кәгазьләр чыгару очракларына карата кулланылмый);

6) административ-эшлекле үзәкләр һәм сәүдә үзәкләре (комплекслар), шулай ук торак йортлар төзү (модернизацияләү, реконструкцияләү).

3.2. Капитал салуларны яклау һәм хуплау турындагы килешү Федераль законның 7 статьясында (хосусый инициатив проект) яисә 8 статьясында каралган процедураларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча төзелә (гавами инициатив проект).

3.3. Гавами-хокукый берәмлекнең аерым актларын (карарлар) куллану үзенчәлекләре (тотрыклыландыру) проектны гамәлгә ашыручы оешмага карата Федераль законның 9 статьясына буенча башкарыла.